# СӘЛАМ ҖЫРЫ

Сәлам сезгә сәлам диеп
Дәшәм, дуслар, бүгендә.
Нинди бәхет сәлам бирү
Әткәм әнкәм телендә.

*Кушымта:*
Зәңгәр күктән әнә безгә
Елмая кояш көлеп,
Ул да безгә сәлам, диеп
Әйтергә тели кебек.

Сәлам бирәм олысына,
Сәлам бирәм кечегә.
Шатлык бүләк итәм шулай
Җирдә һәммә кешегә.

*Кушымта*